**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 октябрь № 770

г. Казань

2017/2018 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләү программаларын – һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләм нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017/2018 уку елына түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләү программаларын – һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын;

Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләү программаларын – һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү күләмнәрен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016/2017 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнарны һәм һөнәри әзерләүне тормышка ашыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативларын раслау турында» 2015 ел, 22 октябрь, 796 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2017 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\770.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 22 октябрь, 770 нче
карары белән расланды

Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләү программаларын – һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) | Уку-өйрәнү вакыты, ай | Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, бер кешегә сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| 13.01.10 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер (тармаклар буенча) | 5 | 7662 | 8661 |
| 19.01.17 | Пешекче, кондитер | 4 | 5419 | 6085 |
| 29.01.08 | Тегү җиһазлары операторы | 3 | 4444 | 5026 |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 5 | 8382 | 9533 |

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 22 октябрь, 770 нче
карары белән расланды

Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләү программаларын – һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү
**КҮЛӘМНӘРЕ**

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) | Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, бер кешегә сум |
|---|---|---|
| «Мамадыш политехника көллияте» ДАҺББУ | | |
| 29.01.08 | Тегү җиһазлары операторы | 40 |
| 35.01.13 | Авыл хуҗалыгы җитештерүгә тракторчы-машинисты | 20 |
| 13.01.10 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер (тармаклар буенча) | 20 |
| 19.01.17 | Пешекче, кондитер | 20 |

___